ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 октябрь 2017 ел № 6172

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары берлән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 31 июлендәге 4348 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 30 июлендәге 3382 номерлы, 2017 елның 16 августындагы 4800 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 1.3.5 пункт өстәргә:

«1.3.5. Муниципаль хезмәт Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторы билгеләгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдалану юлы белән күрсәтелә.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 1.3.6 пункт өстәргә:

«1.3.6. Мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторы билгеләгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдалану юлы белән алынырга мөмкин.»;

3) 1.4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 18 пунктча өстәргә:

«18) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 14 февралендәге 181 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.02.2017, № 8, ст. 1249).».

2. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев